**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СОКУРЫСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422622 с. Сокуры,
ул. Школьная , д.1 , помещение 1
тел: (факс) 8 84378  4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКУРЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422622 Сокуры авылы,
Школьная урамы, 1 нчы йорт,бина 1
тел: (факс) 8 84378   4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү буенча җәмәгать тыңлаулары бәяләмәсе**

Сокуры авылы, Мәктәп урамы, 1 нче йорт.                2024 елның 14 мае
сәгать 10.00 дә башланды сәгать 11.30 да тәмамланды

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге башкарма комитеты инициативасы белән ачык тыңлаулар уздырылды.

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен күздә тоткан үзгәртү буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында» 2024 елның 3 апрелендәге 01 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге Советы башлыгы карары.

Әлеге карар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган 2024 елның 19 апрелендәге 15 (10344) номерлы «Кама ягы» («Камская Новь») газетасында басылып чыкты.

Карар Сокуры авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

- интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча;
- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында;
- Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча.

ачык тыңлауларда катнашучылар проектта тыңлаулар уздыру сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект экспозициясен уздыру сроклары, ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын уздыру даталары, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү сроклары һәм тәртибе, шулай ук башка мәгълүмат турында хәбәр ителделәр.

Сокурысого авыл җирлегендә 8 кеше катнашты. (теркәү кәгазе кушымтада бирелә).

Ачык тыңлауларда беркетмә алып бару Сокуры авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре Э.Д. Писарьга кушылды.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү мөмкинлеге буенча ачык тыңлаулар уздырылды.

Ачык тыңлаулар барышында Сокуры авыл җирлеге Советы башлыгы чыгыш ясады, ул Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен Сокуры авыл җирлегенә кагылышлы өлешендә үзгәртү максатын аңлатты.

"Лаеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территориясе чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында "2005 елның 31 гыйнварындагы 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында"төп мәсьәлә каралды:

9) 22 нче кушымтаның бишенче абзацы түбәндәге редакциядә китерелә:

Сокуры авыл җирлеге чиге Хәерби авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 650 м, канауны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 650 м, төньякка таба 300 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 300 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, канауга кадәр уза,  аннары көнбатышка таба 125 м канау буйлап, аннары көньяк-көнчыгышка таба 120 м, аннары көнбатышка таба 395 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап торак төзелеше буйлап, аннары 70 метр төньяк-көнчыгышка таба канауга кадәр бара, аннары көнбатышка таба 430 м канау буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Сокуры»балык питомнигына керү юлын кисеп үтә, аннары төньяк-көнбатышка таба 1,8 км әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, Сокуры – Хәерби – Травкино автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 10 м уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 40 м әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 650 м урман полосасы буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Сокуры, Хәерби һәм Олы Кабан авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сокуры авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Халык тыңлауларында катнашучылар Сокуры авыл җирлеге өлешендә барлыкка килгән территорияләр чикләренең тәкъдим ителгән вариантлары белән таныштылар. Яңа төзелүче территорияләр чикләре буенча искәрмәләр һәм өстәмәләр килмәде. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Сокуры

авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге территориясе чикләрен үзгәртү буенча тавыш бирделәр.

«Риза» - 8; «Каршы» - 0; «Тыелып калучылар» - 0.

Җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар чыгарылды**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү буенча ачык тыңлауларны билгеләнгән таләпләргә туры китереп үткәрелгән дип санарга.

2. Әлеге беркетмәне Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Ачык тыңлаулар үткәрү буенча документлар пакетын - ачык тыңлаулар билгеләү турында 2024 елның 3 апрелендәге 01 номерлы карарын, 2024 елның 14 маендагы беркетмәне теркәү кәгазен, 2024 елның 14 маендагы 2024 елның 5 маендагы бәяләмәне карау һәм соңгы карарны кабул итү өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге башкарма комитетына ачык тыңлаулар беркетмәсенең төп нөсхәләрен һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне саклауны гамәлгә ашырырга, шулай ук гамәлдәге законнар нигезендә ачык тыңлаулар беркетмәсеннән өземтәләр бирүне гамәлгә ашырырга.

Ачык тыңлаулар рәисе Р.Н. Газизуллин

Сәркатип Э.Д. Писарь